| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.02.2020 с.Старое Дрожжаное № 94

Сатып алуларның план-графикларын формалаштыру, раслау тәртибе турында

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сатып алулар план-графикларын формалаштыру, раслау, мондый план-графикларга үзгәрешләр кертү, сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында сатып алулар план-графикларын урнаштыру, мондый план-графикларга мәгълүмат кертү үзенчәлекләре һәм сатып алуларның план-графикларына карата таләпләр һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым карарлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2009 елның 30 сентябрендәге 1279 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сатып алулар план-графикларын формалаштыру, раслау, мондый план-графикларга үзгәрешләр кертү, сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында сатып алулар план-графикларын урнаштыру, мәгълүматны мондый план-графикларга һәм сатып алуларның план-графигы формасына кертү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 2009 елның 30 сентябрендәге 1279 номерлы карары гамәлен Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар вакытында планлаштыруга таратырга.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы заказчыларына, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу план-графикларын формалаштырганда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 30 сентябрендәге 1279 номерлы карары белән расланган тәртипкә таянып эш итәргә.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар планын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2015 елның 5 октябрендәге 399 номерлы карары;

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу планнарын формалаштыру, раслау һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2015 елның 15 октябрендәге 409 номерлы карары.

4. Әлеге карар, гамәлдәге законнарда каралган очраклардан тыш, 2020 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлегенә йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Д. А. Сатдинов